| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ КУКМОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

7 май, 2024 ел Кукмара ш. № 248

Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендәге 152 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларга, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларына, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренә, рәис урынбасарларына, аудиторларга, муниципаль хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде**:

1. Кукмара муниципаль район Советының 2018 елның 27 апрелендәге 152 номерлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайланулы җирле үзидарә органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә), 2020 елның 30 октябрендәге 13 номерлы, 2021 елның 04 июнендәге 67 номерлы, 2022 елның 18 ноябрендәге 154 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 194 номерлы карарлар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

г) Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 1 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәтнең биләгән муниципаль вазыйфасына карап, авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече

төркеме белгече вазыйфаи хезмәт хакына калдыксыз бүленә торган күләмдә 13323 сум күләмендә вазыйфаи хезмәт хаклары билгеләнә.»;

д) Нигезләмәгә 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Кукмара муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә 2 нче кушымта

МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫНА, МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ УРЫНБАСАРЫНА КОНТРОЛЬ-ХИСАП ОРГАНЫ РӘИСЕНӘ АКЧАЛАТА ТҮЛӘҮ КҮЛӘМЕ

| Вазыйфаның исеме | Акчалата түләүнең күләме (сумнар белән) |
|---|---|
| Муниципаль район Башлыгы | 35272 |
| Башлык урынбасары | 31745 |
| Тикшерү-хисап органы рәисе | 31745 |

е) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Муниципаль хезмәткәркә вазыйфаи окладның 41 процентыннан артмаган күләмдә айлык акчалата түләүләр түләнә, җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле муниципаль хезмәткәрне элек биләгән муниципаль хезмәт вазыйфасыннан түбәнрәк вазыйфаи окладлы муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләп кую очрагыннан тыш, бу очракта акчалата түләү күләмен исәпләү муниципаль хезмәткәрнең акчалата хезмәт хакын элек ул биләгән вазыйфалары буенча акчалата хезмәт хакы күләменә җиткерүне тәэмин итүне исәпкә алып башкарыла».

ж) 3 бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата түләү – хезмәт окладына карата 41 проценттан артмаган күләмдә.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев